**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2016 ел, 15 гыйнвар | № 13

г. Казань

Тарихи җирлекләрдә шәһәр төзү эшчәнлеге мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия төзү турында

Татарстан Республикасы территориясендә тарихи җирлекләрдә шәһәр төзү эшчәнлеген гамәлгә ашырганда мәдәни мирас объектларының сакланышын тәэмин итү максатларында, «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 3 өлеш нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Тарихи җирлекләрдә шәһәр төзү эшчәнлеге мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия (алга таба – Комиссия) төзергә.

2. Теркәлгән Тарихи җирлекләрдә шәһәр төзү эшчәнлеге мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия һәм аның составы турында нигезләмәләрне расларга.

3. Татарстан Республикасы территориясендә тарихи җирлекләр территорияләре чикләрен законнарда билгеләнгән тәртиптә раслаганга кадәр Комиссия территорияләргә мөнәсәбәттә үз эшчәнлеген әлеге карарга теркәлгән кушымтада күрсәтелгән чикләрдә гамәлгә ашыра, дип билгеләргә.

4. Территорияләрендә тарихи җирлекләр урнашкан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә шәһәр төзү өлкәсендә вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда Комиссия карарларын үтәүне тәэмин итүне тәкъдим итәргә.


Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\13.docx

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 15 гыйнвар, 13 нче
карары белән расланды

Тарихи җирлекләрдә шәһәр төзү эшчәнлеге мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия компетенциясе тарала торган территорияләр чикләре


Казан шәһәре




Биләр авылы


ул. Ленинский пер.
Садовая ул.
Подгорная ул.
Советская ул.
ул. Чапаева
ул. Гагарина
ул. Ленина
Советская ул.
ул. Чапаева
ул. Бутлерова
ул. Гагарина
ул. Халикова
Билярск
ул. Урицкого
ул. Ленина
ул. Урицкого
Школьный пер.
Школьная ул.
ул. Кирова
Красноармейская ул.
ул. Куйбышева
ул. Калинина
ул. Ульянова
Октябрьская ул.
ул. Нариманова
ул. Мартынова
Пролетарская ул.
Билярская ул.
ул. Анатолия Серова
Краснобóрская ул.
ул. Халикова
Билярский т

# Болгар шәһәре



Бөгелмә шәһәре




Буа шәһәре


ул. Гагарина
ул. Объездная
ул. Объездная
ул. Бахитова
ул. Колхозная
ул. Ефремова
Буинск
Бикмуразово
Васильевка
Заводская
ул. Г. Ибрагимова
Ветеранский посёлок
Центральная ул.
ул. Шафеева
Красноармейская ул.
ул. Вахитова
Луговая ул.
Советская ул.
ул. Дружбы

Лаеш шәһәре



Мамадыш шәһәре




# Менделеевск шәһәре



Минзәлә шәһәре



Свияжск авылы




Тәтеш шәһәре



Чистай шәһәре



# Алабуга шәһәре




| № | X | Y |
|---|---|---|
| 1 | 2299794 | 470535 |
| 2 | 2299487 | 470897 |
| 3 | 2300289 | 471607 |
| 4 | 2300320 | 471662 |
| 5 | 2300441 | 471795 |
| 6 | 2300447 | 471813 |
| 7 | 2300425 | 471827 |
| 8 | 2300316 | 471863 |
| 9 | 2300096 | 473107 |
| 10 | 2303288 | 472922 |
| 11 | 2303828 | 471588 |
| 12 | 2303858 | 471572 |
| 13 | 2303928 | 471371 |
| 14 | 2303957 | 471321 |
| 15 | 2303949 | 471269 |
| 16 | 2303840 | 471297 |
| 17 | 2303765 | 471297 |
| 18 | 2303622 | 471288 |
| 19 | 2303473 | 471178 |
| 20 | 2303459 | 471127 |

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 15 гыйнвар, 13 нче
карары белән расланды

Тарихи җирлекләрдә шәһәр төзү эшчәнлеге мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия составы

| | |
|---|---|
| Халиков Илдар Шәүкәт улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры |
| Балтусова Олеся Александровна | Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе (килешү буенча) |
| Сибагатуллин Айрат Миңнемулла улы | Татарстан Республикасы мәдәният министры |
| Фәйзуллин Ирек Әнвәр улы | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры |
| Хамаев Азат Кыям улы | Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры |
| Метшин Илсур Рәис улы | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Айзатуллов Азат Касыйм улы | «Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Афанасьев Михаил Павлович | «Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Емельянов Геннадий Егорович | «Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Закиров Линар Рөстәм улы | «Бөгелмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Иванов Анатолий Петрович | «Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Иванов Дмитрий Алексеевич | «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башлыгы (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Козонков Владимир Константинович | «Алексеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Ногаев Камил Әсгать улы | «Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Сәләхов Айдар Фәслах улы | «Минзәлә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Сафиуллов Рәмис Хатыйп улы | «Тәтеш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Тыгин Александр Васильевич | «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Чершинцев Валерий Сергеевич | «Менделеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Сибгатуллин Илдар Нурзад улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыклары идарәсе башлыгы |
| Персова Светлана Глебовна | Татарстан Республикасы мәдәният министры урынбасары |
| Айдарова Галина Николаевна | Казан дәүләт архитектура-төзелеш университетының архитектура теориясе һәм тарихы кафедрасы җитәкчесе, профессор (килешү буенча) |
| Айзатуллин Марат Мансур улы | «Татарстан Республикасының Баш инвестиция-төзелеш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе башлыгы |
| Васильев Николай Георгиевич | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры киңәшчесе |
| Дембич Александр Алексеевич | Казан дәүләт архитектура-төзелеш университетының шәһәр төзү һәм авыл торак урыннарын планлаштыру кафедрасы җитәкчесе, доцент (килешү буенча) |
| Җәберова Фәридә Мөхәммәд кызы | Бөтенроссия тарихи һәйкәлләрне һәм мәдәниятне саклау җәмгыятенең Татарстан төбәк бүлеге рәисе урынбасары (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Кудряшов Василий Александрович | Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе башлыгы |
| Кузьмина Илзирә Ришат кызы | «Татарстан мәдәни мирасы үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе җитәкчесе (килешү буенча) |
| Кутуев Әнәс Абдрахман улы | Биләр дәүләт тарих-археология һәм табигать музей-тыюлыгы директоры (килешү буенча) |
| Лобов Андрей Николаевич | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясе башлыгы (килешү буенча) |
| Логинов Виталий Павлович | «Татарстан Республикасы архитекторлары берлеге» иҗтимагый оешмасы идарәсе рәисе (килешү буенча) |
| Мөхәмәтов Фәргать Вәгыйз улы | Болгар дәүләт тарих-археология һәм табигать музей-тыюлыгы директоры (килешү буенча) |
| Нигъмәтуллин Рөстәм Камил улы | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгының беренче урынбасары (килешү буенча) |
| Новиков Николай Михайлович | Казан дәүләт архитектура-төзелеш университетының архитектураны проектлау кафедрасы җитәкчесе, профессор (килешү буенча) |
| Печенкин Александр Вячеславович | Чистай дәүләт тарих-архитектура һәм әдәбият музей-тыюлыгы директоры (килешү буенча) |
| Прокофьев Евгений Иванович | Казан дәүләт архитектура-төзелеш университетының Архитектура һәм дизайн институты директоры (килешү буенча) |
| Прокофьева Татьяна Георгиевна | Казан шәһәре Баш архитекторы (килешү буенча) |
| Руденко Гөлзадә Рәкыйп кызы | Алабуга дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы генераль директоры (килешү буенча) |
| Силкин Артем Николаевич | «Свияжск утрау-шәһәре» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы директоры (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Усманов Марат Зәкәрия улы | «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының «Иске шәһәр» префектурасы» муниципаль казна учреждениесе территориясе префекты (килешү буенча) |
| Фаттахов Дамир Илдус улы | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының Киров һәм Мәскәү районнары администрациясе башлыгы (килешү буенча) |
| Хөснетдинов Адель Альбер улы | «Татинвестгражданпроект» дәүләт унитар предприятиесе генераль директоры (килешү буенча). |

---

F:\KARAR\2016\13-2.docx

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 15 гыйнвар, 13 нче
карары белән расланды

## Тарихи җирлекләрдә шәһәр төзү эшчәнлеге мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия турында нигезләмә

1. Тарихи җирлекләрдә шәһәр төзү эшчәнлеге мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия (алга таба – Комиссия) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының һәм территорияләрендә тарихи җирлекләр урнашкан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарының (алга таба – җирле үзидарә органнары) әлеге тарихи җирлекләрдә шәһәр төзү мәсьәләләре буенча, мәдәни мирас объектларын һәм табылган мәдәни мирас объектларын реставрацияләү һәм төзекләндерү белән бәйле мәсьәләләрдән тыш, багланышларын оештыру һәм килешеп эшләүләрен тәэмин итү өчен оештырылган орган булып тора.

2. Комиссия үзенең эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

3. Комиссия турында нигезләмә һәм аның составы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

4. Комиссиянең төп бурычлары түбәндәгеләр:

тарихи җирлекләрдә шәһәр төзү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының һәм җирле үзидарә органнарының багланышларын оештыру һәм килешеп эшләүләрен тәэмин итү;

ведомствоара чараларны оештыру;

тарихи җирлекләрдә шәһәр төзү эшчәнлеген гамәлгә ашыру белән бәйле мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салуны камилләштерү мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр әзерләү.

5. Комиссия үзенә йөкләнгән бурычларны тормышка ашыру максатларында түбәндәге төп вазыйфаларны башкара:

җирле үзидарә органнары тарафыннан тарихи җирлекләрдә шәһәр төзү эшчәнлеген аерым җайга салуны гамәлгә ашырганда барлыкка килгән мәсьәләләрне карап тикшерү һәм бу мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр эшләү;

тарихи җирлекләрдә капиталь төзелеш объектларын төзү, төзекләндерү буенча документларны карап тикшерү, шулай ук Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарих һәм мәдәният һәйкәлләрен) саклау, файдалану, популярлаштыру һәм дәүләт саклавы өлкәсендә норматив хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрне үтәүне тәэмин итү буенча тәкъдимнәр эшләү

максатларында әлеге объектларны карап чыгуны гамәлгә ашыру, шул исәптән түбәндәгеләр буенча тәкъдимнәр әзерләү:

капиталь төзелеш объектларын төзүне туктатып тору (туктату);

төзелеше туктатылып торган объектларда төзү-монтажлау эшләрен торгызу;

капиталь төзелеш объектларына проект документларын тәгаенләү;

капиталь төзелеш объектларын җимерү нәтиҗәсендә барлыкка килгән җир кишәрлекләрендә урнаштыру планлаштырылган капиталь төзелеш объектларына проект документлары.

6. Комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

законнарда билгеләнгән тәртиптә Комиссия компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарыннан, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, оешмалардан һәм иҗтимагый берләшмәләрдән кирәкле материалларны соратып алырга;

Комиссия утырышларына Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләр вәкилләрен чакырырга;

Комиссия компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча законнарда билгеләнгән тәртиптә ведомствоара чаралар оештырырга һәм үткәрергә;

Комиссия эшчәнлегенә законнарда билгеләнгән тәртиптә мәнфәгатьле Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләр белгечләрен җәлеп итәргә;

Комиссия эшчәнлегенең аерым юнәлешләре буенча мәсьәләләрне хәл итү өчен эшче төркемнәр, шул исәптән тарихи җирлекләрдә даими эшләүче эшче төркемнәр оештырырга.

7. Тарихи җирлекләрдә даими эшләүче эшче төркемнәр Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары җитәкчеләреннән һәм аларның урынбасарларыннан, шулай ук килешү буенча җирле үзидарә органнары җитәкчеләреннән һәм аларның урынбасарларыннан, мәдәни мирас объектларын саклау, архитектура һәм шәһәр төзү өлкәсендәге белгечләрдән, шулай ук оешмалар, иҗтимагый һәм дини берләшмәләр вәкилләреннән формалаша.

Эшче төркемнәр турында нигезләмәләр һәм аларның составы Комиссия карары белән раслана.

8. Комиссия составын Комиссия әгъзалары белән килештереп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты формалаштыра. Комиссия әгъзалары аның эшендә иҗтимагый башлангычларда катнаша.

Комиссияне Татарстан Республикасы Президенты җитәкли.

9. Комиссия эше регламенты аның карары белән раслана.

10. Комиссия карарлары аның утырышы көненнән соң 10 көн эчендә беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм аны, рәсмиләштерелгән көненнән соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча Комиссия әгъзаларына һәм, зарур булганда, бүтән мәнфәгатьле органнарга һәм оешмаларга тормышка ашыру өчен җибәрәләр.

11. Комиссия эшчәнлеген оештыру-техник яктан тәэмин итү Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

F:\KARAR\2016\13-3.docx